ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АРХАНГЕЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

423182, ТР, Яңа Чишмә районы,
Архангел Бистәсе авылы,
Горький урамы, 21а

СОВЕТ
АРХАНГЕЛЬСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

423182, РТ, Новошешминский район,
село Слобода Архангельская,
улица Горького, 21а

тел.: (8-84348) 38-0-40, факс: (8-84348) 38-0-40, Arhan.Nsm@tatar.ru

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы
Архангел авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

“14” декабрь 2018 нче ел №50-108

“Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Архангел авыл җирлеге Советының 2018 нче елның 24 нче сентябрендәге “Яңа Чишмә муниципаль районы Архангел авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең вазый фаиокладлары күләмнәрен, айлык һәм башка өстәмәтүләүләр күләмен һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибен билгелә үтурында” 48-95 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында”

2003 нче елның 6 нчы октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 131-ФК номерлы Федераль кануны, 2013 нче елның 28 нче декабрендәге “Иминият пенсияләре турында” 400-ФК номерлы Федераль кануны, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 нче елның 28 нче мартындагы“Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларына, сайлап куела торган вазыйфаи затларына, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренә, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләргә хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында” 182 нче карары белән расланганТатарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 нче елның 17 нче октябрендәге “Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларына, сайлап куела торган вазыйфаи затларына, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренә хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативларына үзгәрешләр кертү хакында” 940 номерлы карары, Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Архангел авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Архангел авыл җирлеге Советының 2018 нче елның 24 нче сентябрендәге “Яңа Чишмә муниципаль районы Архангел авыл җирлегендәмуниципаль вазыйфаларны даими нигездә биләгән муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен, айлык һәм башка өстәмә түләүләр һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында 48-95 номерлы карары белән расланган Муниципаль вазыйфаларны даими нигездә биләгән затларга акчалата бүләкләү күләменә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
1 нчекушымтаның 2 пунктында «4,65» саннарын " 6,72»саннарынаалмаштырырга.
2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Архангел авыл җирлеге Советының 2018 нче елның 24 нче сентябрендәге “Яңа Чишмә муниципаль районы

Архангел авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен, айлык һәм башка өстәмә түләүләр күләмен һәм аларны гамәлгә ашыру турында" 48-95 номерлы карарының 13 нче кушымтасын "Тиешле еллар эшләгән өчен муниципаль пенсиягә чыгу белән бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган бүләкләү тәртибе һәм шартлары тәртибен" яңа редакциядә бәян итәргә:

"1. Муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләгән затка, муниципаль хезмәткәргә, тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгу белән бәйле рәвештә, пенсиягә өстәмә хокукы булганда, бер тапкыр акчалата бүләк түләнә.

Муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләгән затка бер тапкыр бүләкләү биләгән вазыйфасы буенча билгеләнгән ун тапкыр айлык акчалата бүләк күләмендә түләнә.

Муниципаль хезмәткәргә бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләк муниципаль хезмәт вазыйфасы буенча эштән азат ителгән көнгә билгеләнә торган айлык акчалата керемнең биш тапкыр күләмендә түләнә,муниципаль хезмәт стажы 15 ел булганда һәм муниципаль хезмәтнең һәр киләсе тулы елы өчен өстәмә рәвештә 0,5 айлык акчалата керем, ул айлык акчалата керемнең ун күләменнән артмаска тиеш.

Муниципаль хезмәт стажы муниципаль вазыйфадан яки муниципаль хезмәттән азат ителгән көнгә билгеләнә.

2. Бер тапкыр бирелә торган бүләкләү күләмен билгеләгәндә исәпкә алына торган муниципаль хезмәткәрнең айлык акчалата тоту составына түбәндәгеләр кертелә: вазыйфаи оклад, класс чиннары өчен айлык өстәмә, муниципаль хезмәтнең махсус шартлары өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә түләү

3. Бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү турындагы карар тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгу белән бәйле рәвештә эштән азат итү турындагы карар белән бер үк вакытта рәсмиләштерелә.

4. Бер тапкыр бирелә торган бүләкләү, пенсиягә чыгу белән бәйле рәвештә, муниципаль хезмәткәр эштән азат ителгән көннән бер айдан да соңга калмыйча, муниципаль хезмәткәрләр турыдан-туры эштән чыгар алдыннан хезмәт итә торган орган тарафыннан түләнә.

5. Тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгу белән бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләк хезмәт кенәгәсендә билгеләнеп куела. Гражданга тиешле елларны эшләгән һәм аннан соң муниципаль хезмәт туктаткан өчен пенсиягә чykканнан соң бер тапкыр бирелә торган бүләкләү яңадан муниципаль хезмәткә урнашкан очракта кабат түләнми.

6. Бер тапкыр бирелә торган бүләкне түләү җирле бюджет акчаларыннан гамәлгә ашырыла".

3. Әлеге карар 2018 нче елның 1 нче октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла һәм үз көченә керә.

4.Әлегекарарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматрәсми порталының рәсмисайтында" "Интернет" мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендә") http://pravo.tatarstan.ru., Яңа Чишмә муниципальрайонының рәсмисайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru/. Бастырып чыгарырга (халык каигъланитәргә

5. Әлеге карарның үтәле шентикшерепторуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Архангел авыл җирлеге Советының бюджет, салымнар һәм финанслар буенчадаими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә
муниципаль районы Архангел
авыл җирлеге башлыгы Н.А.Сердюк